ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 05.11.2020 г. Казань № 181-38/кс-2020

«Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 № 10-120/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2021 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга 2021-2023 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 05.12.2018 № 10-120/кс номерлы карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.10.2019 №10-8/кс, 20.11.2019 №10-87/кс карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.12.2018 № 10-120/кс
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.11.2020 № 181-38/кс-2020
карары редакциясендә)

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Казан шәһәре | | |
| 1 | «Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 49,51 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 50,11 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 50,11 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 51,64 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 51,64 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 51,83 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 51,83 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 53,99 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 53,99 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 54,26 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.12.2018 № 10-120/кс
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.11.2020 № 181-38/кс-2020
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суларны агызуны хәл итүче оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2019 | 1057,47 | X | - | 8,75 | 2,38 |
| | | 2020 | X | 1 | - | 8,75 | 2,38 |
| | | 2021 | X | 1 | - | 8,75 | 2,38 |
| | | 2022 | X | 1 | - | 8,75 | 2,38 |
| | | 2023 | X | 1 | - | 8,75 | 2,38 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге